ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» 12 2018г.** **№947**

2019 елга "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль -педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Мәгариф турында»гы 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге «Татарстан Республикасында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигать-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге һәм күп профильле өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү Нигезләмәсен раслау турында"гы №939 карары һәм "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2019 елга расларга:

"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны;

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм

культурологик юнәлешле һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар буенча төзәтү коэффициенты - 0,5 күләмендә.

2. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы индексациясе белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

А.В. Сучкова
2-80-12

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расландылар
«__» декабрь 2018 ел № ____

**“Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлегеидә балаларның өстәмә белем бирү оешмаларында туристлык-тугаи якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф оешмаларының өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Урнашкан урыны | Норматив чыгымнар, 1 укучыга – бер елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Беренче уку елы | Икенче уку елы | Өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгати-эстетик | Шәһәр җире | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | Авыл җире | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | Шәһәр җире | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | Авыл җире | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | Шәһәр җире | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | Авыл җире | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристик-төбәкне өйрәнү | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | Авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | Авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | Авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | Шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | Авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | Шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | Авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | Авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |